ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.04.2019 Олы Кайбыч авылы № 176

Муниципаль район составына керә торган авыл җирлекләре
бюджетларына җирлекләрнең чыгым вазыйфаларын финанс
белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районы бюджетыннан башка бюджетара
трансфертларны бирү Тәртибен раслау турында

Һөнәри салымга салым потенциалы үсешен стимуллаштыру максатында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019нчы елның 28 нче мартындага 233 нче номерлы «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына җирлекләрнең чыгым вазыйфаларын финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертларны бирү Тәртибен раслау турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР КЫЛА:

1. Кушымта итеп бирелә торган Муниципаль район составына керә торган авыл җирлекләре бюджетларына җирлекләрнең чыгым вазыйфаларын финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджетыннан башка бюджетара трансфертларны бирү Тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында” урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Финанс бюджет палатасына йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров

Татарстан Республикасы Кайбыч

муниципаль районы Башкарма

комитетының 2019нчы елның

«15 »нче апрелендә чыккан 176нчы

номерлы карарына Кушымта №1

**Муниципаль район составына керә торган авыл җирлекләре бюджетларына җирлекләрнең чыгым вазыйфаларын финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджетыннан башка бюджетара трансфертларны бирү**

**Тәртибе**

1. Әлеге Тәртип муниципаль район составына керә торган авыл җирлекләре бюджетларына җирлекләрнең чыгым вазыйфаларын финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджетыннан башка бюджетара трансфертларны бирү механизмын билгели. (алга таба – җирлекнең башка бюджетара трансфертлары).

2. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында муниципаль район составына керүче авыл җирлекләре бюджетларына җирлекләрнең чыгым вазыйфаларын финанс белән тәэмин итү һөнәри салымга салым потенциалы үсешен стимуллаштыру максатында бирелә.

3. Башка бюджетара трансфертлар авыл җирлекләре бюджетларына агымдагы финанс елының бюджет ассигнованияләре күләме чикләрендә әлеге максатларга агымдагы финанс елына һәм план периодына Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджеты турында карарда каралганча квартал саен алдагы кварталдан соң килә торган айның 30нчы числосына кадәр бирелә.

4.Әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган чараларны Төп бүлүче - Кайбыч муниципаль районы Финанс бюджет палатасы (алга таба – Финанс бюджет палатасы).

5. Башка бюджетара трансфертларны бүлү Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

6. Башка бюджетара трансфертлар күләме җирлек өчен тиешле квартал өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019нчы елның 28 нче мартындага 233 нче номерлы «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына җирлекләрнең чыгым вазыйфаларын финанс белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертларны бирү Тәртибен раслау турында» карары белән билгеләнгән методика нигезендә башкарыла.

7. Муниципаль район составына керә торган авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары булып

җирлекнең башка бюджетара трансфертлар хисабына гамәлгә ашырыла торган чыгым юнәлешләрен күрсәтүче норматив-хокукый актлары булу тора.

8. Башка бюджетара трансфертлар Финанс бюджет палатасы тарафыннан җирлек бюджетларына Татарстан Республикасы буенча территориаль Федераль казначей Идарәсе органнарының җирле бюджетларны касса белән тәэмин итү өчен ачылган счетларына күчерелә.

9. Җирлекнең Башкарма комитеты (алга таба – башкарма комитет) Финанс бюджет палатасына башка бюджетара трансфертларны куллану турында Финанс бюджет палатасы билгеләгән тәртиптә хисап бирә.

10. Агымдагы финанс елының 1 гыйнварына кулланылмаган, әлеге Тәртип нигезендә алынган башка бюджетара трансфертлар, агымдагы финанс елының беренче 15 эш көнендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы керемена кире кайтарылырга тиеш.

Финанс бюджет палатасының башка бюджетара трансфертларга ихтияҗ булу турындагы карары нигезендә, агымдагы финанс елында кулланылмаган башка бюджетара трансфертлар калдыгы күләменнән артмаган чаралар агымдагы финанс елында алданрак башка бюджетара трансфертлар бирү шартларына туры китереп җирлек бюджеты чыгымнарын тәэмин итүгә бирелгән җирлек бюджетына кайтарылырга мөмкин.

Әлеге Тәртип нигезендә алынган, кулланылмаган, башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы керемена кире кайтарылмаган очракта, күрсәтелгән чаралар Россия Федерациясе финанслар Министрлыгы билгеләгән гомуми шартларны саклап Финанс бюджет палатасы билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы керемена алына.

11. Башкарма комитет һәм вазыйфаи затлар бирелә торган хисап мәгълүматларының дөреслеге һәм башка бюджетара трансфертлар бирү шартларының үтәлеше өчен канунчылык нигезендә җаваплы.

12. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары сакланмаган очракта әлеге чаралар Россия Федерациясе бюджет канунчылыгы белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы керемена күчерелергә тиеш.

13. Әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган башка бюджетара трансфертларны максатчан куллануны контрольләүне Финанс бюджет палатасы гамәлгә ашыра.